РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«6» декабря 2023г. г. Альметьевск №131

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге 60 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 02 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2016 елның 28 декабрендәге 60 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2017 елның 30 мартындагы 74 номерлы, 2017 елның 05 маендагы 78 номерлы, 2017 елның 31 маендагы 83 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 91 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 114 номерлы, 2018 елның 13 декабрендәге 135 номерлы, 2019 елның 25 мартындагы 146 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 192 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 209 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 12 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 53 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 77 номерлы, 2023 елның 29 мартындагы 101 номерлы, 2023 елның 11 августындагы 115 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. карарга 4 бүлекнең кушымтасында «Муниципаль хезмәткәрләргә классны чиннар бирү, муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына»:

- 4.6 пунктның 4.6.1 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- 4.10 пункты үз көчен югалткан дип танырга;
- 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.13. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турындагы карар, 4 бүлекнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына кирәкле барлык документлар белән сыйныф чинын бирү

турындагы тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Ф.Р. Шәйхетдинова).

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов